ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**21.09.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 2482**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 маендагы 1181 номерлы карары белән расланган, Муниципаль учреждениеләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре гамәлдән чыгуын тану турында»гы 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 нче номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 31 маендагы 1181 номерлы карары белән расланган, «Муниципаль учреждениеләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 6 мартындагы 436 номерлы , 2022 елның 26 мартындагы 436 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән), Муниципаль учреждениеләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә, әлеге карарда кушымта каралганча, үзгәрешләр кертергә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан муниципаль учреждение булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенең "б" пунктчасының беренче, алтынчы һәм ундүртенче абзацлары, 4 пунктның "ж" пунктчасының бишенче абзацы нигезләмәләре түбәндәгеләргә карата кулланыла:

2024 елның 1 гыйнварыннан башлап, финанс белән тәэмин итү чыганагы федераль бюджет акчалары булган Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләргә;

2025 елның 1 гыйнварыннан башлап,Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган башка субсидияләргә;

б) Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан муниципаль учреждениеләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктындагы «а(1)» пунктчасы нигезләмәләре, 2023 елның 1 гыйнварыннан башлап Татарстан Республикасы бюджетыннан, Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан бирелә торган субсидияләргә карата кулланыла.

3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. Р. Ганиев

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 21 сентябрендәге 2482 номерлы карарына кушымта

Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, муниципаль учреждениеләр булмаган, коммерциягә карамаган оешмаларга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә (алга таба - Тәртип):

1.1.2 пунктның г) пунктчасында «максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

1.2. 3 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр бирү турында гомуми нигезләмәләрне билгеләү максатларында түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) хокукый акт максатлары өчен кулланыла торган төшенчәләр (кирәк булганда);

б) милли проект (программалар) , шул исәптән тиешле милли проект (программалар) составына керүче федераль проект яисә федераль проект, дәүләт (муниципаль) программасы максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган региональ проект исеменнән чыгып, әгәр субсидияләр тиешле проектларны, программаларны гамәлгә ашыру максатларында бирелсә, субсидияләр бирү максатлары;

в) бюджет акчаларын алучылар буларак Россия Федерациясенең бюджет законнары нигезендә тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр бирүгә бюджет йөкләмәләре лимитлары билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет акчаларын баш бүлүче (алга таба - бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче) функцияләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органы яисә оешма исеме;

г) субсидия алучының исеме, әгәр ул Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының резерв фондыннан файдалану максатларында бюджет турындагы карар, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты кабул итә торган карар нигезендә билгеләнгән булса, яисә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының карарлары белән билгеләнгән очракта, субсидия рәвешендә грант алучының исеме;

д) күрсәтелгән критерийлардан чыгып сайлап алына торган субсидияләрне алучыларның категориясен һәм (яисә) сайлап алу критерийларын (әлеге пунктның «г» пунктчасында каралган очраклардан тыш);

е) әлеге Тәртипнең 4 пунктындагы «а» пунктчасы нигезендә сайлап алуны үткәрү ысулы, әгәр субсидияне алучы сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнсә;

ж) бюджет турында карар проектын (бюджет турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында карар) төзегәндә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - бердәм портал) (бердәм портал бүлегендә) субсидияләр турында белешмәләр урнаштыру турында мәгълүмат.»;

1.3 4 нче пунктта:

а) б) пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) бердәм порталда сайлап алуны уздыру турында игълан урнаштыру датасы (дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең мәгълүмат системасына сайлап алу үткәрелгән очракта (алга таба - «Электрон бюджет» системасы) яисә сайлап алуны үткәрү (сайт бите күрсәткечен бердәм порталда урнаштыру белән) тәэмин ителә торган башка сайтта, шулай ук, сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтеп, «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бюджет чараларын алучы буларак, баш бүлеп бирүченең рәсми сайтында кирәк булганда:»;

б) б) пунктчасының алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«сайлап алуны үткәрү тәэмин итеүчеләр торган «Электрон бюджет» системасының яисә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге башка сайтның домна исемен һәм (яисә) битләре күрсәткечләрен»;

в) б) пунктчасының ундүртенче абзацында «бердәм порталда» сүзләреннән соң «(системада «Электрон бюджет» системасында сайлап алу уздырылган очракта) яисә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителәә торган башка сайтта (сайт битенең күрсәткечләрен бердәм порталда урнаштырган очракта)» сүзләрен өстәргә;

г) в) пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«сайлап алуда катнашучы үзләренә карата экстремистик эшчәнлеккә яисә террорчылыкка катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә , йә үзләренә карата массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында белешмәләр булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормаска тиеш.»;

д) «ж» пунктчасының бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

тәкъдимнәрне (гаризаларны)карау нәтиҗәләре турында мәгълүматны урнаштыру сроклары "бердәм порталда ("Электрон бюджет"системасында сайлап алуны уздырган очракта) яисә сайлап алу үткәрелә торган башка сайтта (сайт битенең күрсәткечен бердәм порталга урнаштырып), шулай ук "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлеп бирүченең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә ала торган :";

1.4. Тәртипкә түбәндәге эчтәлекле 4.2 пункт өстәргә:

«4.2. Әгәр хокукый актта сайлап алуны уздыру турында, тәкъдимнәрне (гаризаларны) карау нәтиҗәләре турында, сайлап алуда катнашучылар һәм сайлап алу нәтиҗәләре турында , шул исәптән килешүләрне сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат, чикләнгән мәгълүмат буларак күрсәтелсә, әлеге мәгълүмат бердәм порталда урнаштырылмый»;

1.5. 5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Хисап бирүгә таләпләр субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 4.1 пунктындагы «м» пунктчасында күрсәтелгән нәтиҗә һәм күрсәткечләр кыйммәтләренә ирешү турында (мондый күрсәткечләр билгеләнгәндә), финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган (ләкин кварталга кимендә бер тапкыр) чыгымнарны гамәлгә ашыру турында, субсидияләрнең тиешле төр субсидия өчен Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасында билгеләнгән килешүләрнең типлаштырылган формалары буенча хисап бирү тәртибен һәм срокларын билгеләүне , шулай ук бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлеп бирүченең килешүдә субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисап бирү срокларын һәм формаларын (кирәк булганда) билгеләргә хокукын күз алдында тота.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 2 пункты нигезендә бирелә торган, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү таләбе кирәк булганда хокукый актта билгеләнә»;

1.6. 6 нчы пунктта:

а) беренче абзацта «максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

б) «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а)бюджет акчаларын алучы буларак баш бүлүче тарафыннан субсидия алучының субсидияләр бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәлүен тикшерү турында, шулай ук Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268.1 һәм 269.2 статьялары нигезендә муниципаль финанс контроленең вәкаләтле органнары тарафыннан тикшерү турында таләп»;

в) түбәндәге эчтәлекле «а(1)» пунктчасы өстәргә:

«а(1))Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәмамлау фактын чагылдыручы вакыйгалардан чыгып (контроль нокта)субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүгә мониторинг уздыру таләбе;»;

г) «б» пунктчасының беренче абзацында «максатларын» сүзен төшереп калдырырга.